РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕТУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ТОРМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 57-3-12, факс 57-3-12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24 .02. 2021** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Олы Тормы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә **КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2021 елның 9 мартында 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча Кече Тормы авылында гражданнар җыенын үткәрергә.

2. . Гражданнар җыенына чыгарылачак мәсьәләне раслау:

“Сез, карардагы “1000 сум күләмендәге” сүзләрен “1250 сум күләмендә” дигән сүзләргәталыштырырга ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тормы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Н.Г. Салихов**